**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2021 елның «29» мартыннан № 154

### 2021 елның II кварталына гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының уртача бәясен раслау турында

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак – коммуналь хуҗалык министрлыгының «2020 елның II кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2009 елның 13 мартындагы 122/пр номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак – коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасының «2020 – 2025 елларга Яңа Чишмә муниципаль районында Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында, авыл җирендә яшәүче яшь гаиләләрнең торак шартларын федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты исәбенә яхшырту чараларын үткәрүгә социаль түләүләр күләмен хисаплап чыгару өчен 2021 елның II кварталына торакның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе 32660 сум 00 тиен күләмендә дип расларга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль

районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фәсахов